ЮЛЛАРГА – МИЛЛИАРДЛАР

Илкүләм проект кысасында төзекләндереләчәк һәм төзеләчәк юллар билгеле

> 2

РӘХМӘТ ҺӘМ СОКЛАНУ

Нәкыя Гыйләҗева – шәхес кадере һәм хәтер турында

> 3



СМӘЕЛ «ЙОЛДЫЗ»Ы

Океан артында яшәүче хоккейчы Әмир Шакировны Балтачта өчпочмак пешереп көтеп торалар

> 4

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ

«Әле менә тагын бер мәшәкать килеп чыкты...»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 40 (29007) | Чәршәмбе | 22 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

ТЕЛДӘН ТӨШМӘГӘН СЫНАУ

НИНДИ ХАТАЛАРНЫ КАБАТЛАМАСКА?

БДИ – 2023

Бердәм дәүләт имтиханын алдан бирү этабы башланды. Ул 19 апрельгә кадәр дәвам итәчәк. Быелгы чыгарылыш укучылары күбрәк нинди фәннәрне сайлаган? Туган телдән имтиханнарга игътибар артканмы? Хөкүмәт йортында узган брифингта Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин кагыйдәләрне янә искә төшерде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Имтихан кала: аннан берәү дә баш тартырга җыенмый.Кагыйдәләр дә шул ук. Кайбер фәннәрдән биремнәрдә генә үзгәрешләр бар. Әйтик, тарихтан сорауларның 20 проценттан артыгы Бөек Ватан сугышына бәйле булачак.

Күбесе математика (профильле) сынавын сайлаган. Әлеге фәнне укучыларның яртысыннан күбрәге (8092) тапшырачак. Искәртәбез: математикадан база сынавын биреп, вузга профильле юнәлешләргә укырга кереп булмый. Икенче урында – җәмгыять белеме (6419). Өченчедә – информатика (3495). Болары – иң популярлары. Ә менә физика (381гә), химия (21) кебек техник фәннәрне сайлаучылар кимегән. Сәбәбе нидә?

– Бу кимү Россия күләмендә шулай. Безгә югары уку йортларына инженерлык һөнәрләренә имтиханнар тапшыруны үзгәртергә кирәк. Моңа кадәр гуманитар юнәлешкә игътибар бирелде. Төгәл фәннәргә кызыксыну уяту өчен, профильле сыйныфлар ачуны күздә тотабыз. Республикада «Казаныш» программасын кабул итәргә җыенабыз. Анда физика, математика, химия, биология юнәлешләрендә профильле сыйныфлар ачу каралган. Бу медицина, авыл хуҗалыгы, сәнәгатьне үстерү буенча да мөһим. Әлеге фәннәргә игътибарны арттыру кирәк. Шулай итеп кенә мөнәсәбәтне үзгәртеп була, – дип үз фикерен җиткерде Илсур Һадиуллин.

Министр әйтүенчә, чыгарылыш укучылары сынауларны яхшы бирсен өчен, республикада барлык шартлар тудырылган. Узган ел безнекеләрнең рус теле (72,7 балл), математикадан (65,27) уртача күрсәткечләре ил буенча югарырак булган.

– Һәр ел саен 1 сентябрьдән бигрәк тә 10–11 нче сыйныфларда имтиханнарга ныклы әзерлек алып барыла. Әмма бу көчләп тагу булырга тиеш түгел. Болай эшләү дөрес булмаячак. Укытучылар үз эшен башкара, өстәмә дә шөгыльләнә. Бу очракта репетитор кирәкме-юкмы – моны әти-әниләр һәм балалар үзләре хәл итә, – диде ул.

Узган ел 11 нче сыйныфны тәмамлаучылар арасында татар теленнән сынауны нибары бер укучы гына тапшырган иде. Быел теләк белдерүчеләр – сигез. Алар – Әгерҗе, Әлмәт, Балтач, Нурлат, Казанның Авиатөзелеш һәм Совет районы укучылары. Арада берсе әдәбиятны да сайлаган. 9 нчы сыйныф укучылары арасында туган телне 2501 бала сайлаган. Узган ел белән чагыштырганда бу сан ике мәртәбә артык.

– Ничек кенә булмасын, туган телләр – татар, мари, мордва, чуаш һәм башка телләргә республика тарафыннан игътибар һәрвакыт булды, алга таба да дәвам итәчәк. Бу безне сөендерә, – диде Илсур Һадиуллин.

Күптән түгел министр үзе дә Яшел Үзәндә рус теленнән сынау тапшырып карады. Анда әти-әниләр өчен махсус акция оештырылган иде.

– Җиде биремгә җавап бирергә һәм инша язарга туры килде. Аңлашыла, без инде мәктәпне 40 ел элек тәмамлаган. Шулай да бөтенесен искә төшердек, – диде Илсур Һадиуллин. – Әти-әниләрнең балаларына таләпләре югары хәзер. Һәрберсе үз баласы турында югары фикердә: аны бик яхшы белә дип уйлый. Ләкин тормыш башканы күрсәтә. Шуңа күрә әти-әни, имтихан килеп җиткәч: «Син 90–100 баллга бирергә тиеш», – дип мәҗбүр итәргә тиеш түгел. Бу – бик куркыныч әйбер. Тормышта имтиханнар бик күп, моның белән генә дөнья бетми. Бу – беренче генә сынау. Тырышып укыган балага аның бернинди авырлыгы да юк. Алда да, артта да камера, әлбәттә. Алар хәзер урамда да, бөтен җирдә дә бар. Моннан куркырга кирәкми. Әгәр боргалана, кесәңне капшый башлыйсың икән, шикләнү тудырасың. БДИда сиңа берәү дә ярдәм итә алмый. Күчереп эләккәч, бала бер елга соңга кала. Кирәкми андый нәрсә эшләргә. Тырышсыннар, бирсеннәр. Теләгем шул: балалар бер дулкында булсын, бер-берсен аңласын. Әти-әниләр балаларын тынычландырырга тиеш.

Имтиханнарның төп этабы 26 майда башланып, 1 июльгә кадәр дәвам итәчәк. Рус теле һәм математиканы (база) кабат 6–19 сентябрьдә тапшырырга мөмкин.

Сан

Быел бердәм дәүләт имтиханнарында 16546 укучы катнашачак. Шуларның 15179ы мәктәпне быел тәмамласа, калганнары – узган елгы (9) һәм быел урта һөнәри уку йортын (184) тәмамлаучылар.
Узган ел 26 укучы аттестат алмыйча калган иде.

Ишәябез

Татарстан узган елда Идел буе федераль округында халык саны арткан бердәнбер төбәккә әйләнгән. Россиядә яшәүчеләрнең саны турында яңартылган мәгълүматлар шул хакта сөйли.

2022 елда Түбән Новгородта халык саны бигрәк тә нык кимегән – 27101 кешегә. Башкортстанда (халык саны буенча округта беренче урында тора) – 14021 кешегә. Мари Илендә кимү иң аз дәрәҗәдә – 4030 кешегә.

Исегезгә төшерәбез: узган елда Татарстанда даими яшәүчеләр саны 1541гә артып, 4001625 кешегә җиткән. Бу мигрантлар күбәюгә (9683 кеше) бәйле.

Шауласын урман

Республика территориясенең 17,5 процентын урманнар били. 2 проценттан артыграгын ышыклагыч агач полосалары алып тора. Шулай итеп, республика җирләренең 19,6 процентын урман-агачлыклар тәшкил итә. Урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтүенчә, кешеләргә уңайлырак шартлар тудыру өчен урман территориясе 25% булырга тиеш. Хәзерге вакытта республикада бер кешегә уртача 30 сутый урман мәйданы туры килә. Ә илдә бу күрсәткеч 5,3 гектарга тигез.

Министр билгеләп үткәнчә, Татарстанда урманнар бүленеше тигез түгел. Аларның өлеше 40 проценттан арткан урыннар да бар. Әйтик, Нурлат районында шулай. Ә менә Чүпрәле һәм Чистай районнарында урманнар бөтенләй юк. Равил Кузюров басым ясап әйткәнчә, урман-агачлыклар мәйданын нибары 1 процентка гына арттыру өчен дә 65 мең гектар мәйданда яңа үсентеләр утыртырга кирәк. Моның өчен йөзләрчә ел узарга мөмкин.

Керемнәре арткан

Татарстанда үзмәшгульләр соңгы өч ел эчендә керемнәрен 18 тапкыр арттырган. Агымдагы ел башына алар барлыгы 75 миллиард сум акча эшләгән. Ә 2021 елның гыйнварына бу сан 4,1 миллиард сум гына булган.

Икътисад һәм сәүдә министрлыгы хәбәренә караганда, махсус салым режимы кертелгәч, республикада мондый эшмәкәрләр саны 4 тапкыр арткан. 2020 елның гыйнварына алар 61,9 мең кеше булса, быел 1 гыйнварга 234,2 меңгә җиткән. Бүгенгә 247 мең кеше үзмәшгуль булып санала.

2019 елда, пилот төбәк буларак, Татарстанда үзмәшгульләргә махсус салым режимы кертелде. Шуңа күрә алар төрле дәүләт ярдәме чараларыннан – ташламалы микрозаемнардан һ.б. файдалана.

Узган елда Татарстанда барлыгы 234,2 мең кеше үзмәшгуль буларак исәптә торган. Ел башыннан бирле аларның барлык кереме 31,4 миллиард сум тәшкил итә.

Бала укытуга тоталар

Татарстанда ел башыннан бирле меңнән артыграк гаилә балаларын укытуга ана капиталын тоткан. Социаль фондның республикадагы бүлеге, ата-аналар балаларын укытуга дәүләт ярдәмен тизрәк, җиңелрәк җибәрә алсыннар өчен, мәгариф оешмалары белән элемтәдә тора. Барлыгы 1800 шундый оешма белән мәгълүмат алышу эшен алып бару күздә тотыла.

Хәзерге вакытта Социаль фонд бүлеге 29 югары, 99 урта махсус уку йорты, шулай ук 1724 балалар бакчасы белән мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешү төзегән. Аның җитәкчесе Эдуард Вафин әйтүенчә, моңа кадәр ана капиталын баласын укытуга тотарга ниятләүчеләргә уку йортыннан түләүле хезмәтләр турында килешү күчермәсен фондка илтеп тапшырырга кирәк булган. Бүген исә фондка гариза гына тапшырырга кирәк. Башка мәсьәләләрне ул мөстәкыйль хәл итә.

Җил вакытында исәр

Татарстанда апрель, майда, шулай ук җәйнең өч ае дәвамында айлык уртача һава температурасы нормада булачак. Әмма, Гидрометеоүзәк фаразларына караганда, сентябрь аенда нормадан җылырак булырга мөмкин.

Бездә апрель ае өчен айлык уртача температура – 5,4 градус җылы, майда – 13,6, июньдә – 17,8, июльдә – 19,9, августта 17,7 градус җылы тәшкил итә. Сентябрь ае өчен республикада айлык уртача температура нормасы – 11,9 градус җылы.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматлары буенча, 24–26 мартта – җомга, шимбә һәм якшәмбедә уртача температура нормадан 6–8 градуска югарырак булачак. Көндезге сәгатьләрдә һава температурасының +11 градуска җитүе күтәелә.

Бердәмлек

Уртак ярдәм

Акча һәм кирәк-ярак, азык-төлек һәм җылы сүз. Предприятие, хәрби бергәлекләр, битараф булмаган кешеләр – барысы да махсус хәрби операциядә катнашучыларга теләктәшлек йөзеннән ярдәмгә кушыла. Татарстанда бу эш нинди юнәлешләрдә башкарыла?

Мәгълүм булганча, ил Президенты Владимир Путин махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм анда һәлак булучыларга ярдәм итү өчен дәүләт фонды булдырырга тәкъдим итте. Әлеге оешма төрле юнәлештә ярдәм күрсәтү, дәвалану һәм реабилитация мәсьәләләрен хәл итү белән шөгыльләнергә тиеш.

Татарстан махсус операция зонасына 1,5 млрд долларлык гуманитар ярдәм җибәргән. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов хәбәр иткән иде.

kzn.ru

«Гуманитар йөкне турыдан-туры хәрби зонага китерү, Лисичанск шәһәренә ярдәм күрсәтү буенча эш алып барыла. Кайбер район башлыклары үзләре үк йөкне тиешле урынга алып бару белән шөгыльләнде. Кыска вакытлы ялга кайткан хәрбиләрне лаеклы итеп каршы алу да кирәк», – диде Рәис.

Матди ярдәм. Акчалата ярдәмгә килгәндә, Татарстаннан мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләре бала туу һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә ай саен түләнә торган пособие ала. 2023 елда пособие запастан чакырылган 15 хәрбинең йөкле хатынына һәм 400дән артык гаиләгә (677 балага) билгеләнгән.

Ахыры 3 нче биттә >

Ничек булышырга?

Халыкка ярдәм:
- ✓«Ярдәм», «День добрых дел», «Душа России» фондлары;
- ✓«Игелекле Казан» проекты, #БезБергә (#МыВместе) акциясе;
- ✓«Яшь Гвардия»нең гуманитар штабы.

Мобилизацияләнүчеләргә ярдәм:
- ✓«Барысы да Җиңү өчен!» проекты;
- ✓«Зәкят» фонды;
- ✓«Ярдәм янәшә!» хәрәкәте;
- ✓Татарстан десантниклары союзы, «Золотые руки ангела» хәрәкәте.



Бердәм «кайнар элемтә» телефоны: **8-800-350-02-16**.

Сүзгә-сүз

Михаил ИВАНОВ, Россиянең сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары:

Көнбатыш чикләүләргә карамастан, илдә чит ил товарларына бәйле вазгыять бик нык үзгәрмәде. Күп кенә чит ил компанияләре Россиядә эшләвен дәвам итә, ә киткән брендларны параллель импорт аша кертәләр. Россиялеләр безнең илдә ясалган товарларга өстенлек бирә башлады. Кайбер сәүдә челтәрләрендә Россия җитештергән товарлар күләме 2 тапкыр арткан, сату күләме дә үсте.

(«ChemiCos 2023» күргәзмәсендәге чыгышыннан)

БӘХЕТ ӨЧЕН КҮПМЕ АКЧА КИРӘК?

«СберСтрахование» компаниясе оештырган сораштыру әнә шул сорауга җавап эзли.

Уртача керем >>
96 мең сум

Хатын-кызлар >>
108 мең сум
(аена)

Ир-атлар >>
84 мең сум
(аена)



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БАНК ТОТАРГАМЫ, БОР КАРБИДЫ ҖИТЕШТЕРЕРГӘМЕ?

Финанс спекулянтлары, зур мәтәлчек атып, упкынга очуларын дәвам итә. Үзәк банкларның мул итеп акча басулары, бөлгән банклар милкен сату әлегә көтелгән нәтиҗәләрне биреп бетерә алмый. Вазгыять, киресенчә, бу юллар авторы әйткән якка таба авыша: чылбыр реакциясе туып килә. Безнең фаразны дүшәмбе көнне JPMorgan – дөньяның иң зур банкларыннан берсе булган трансмилли финанс конгломераты аналитиклары кабатлады: Credit Suisse кәгазьләре очсызланудан килгән югалтулар чылбыр реакциясе куркынычы тудыра, диделәр. Дөрестән дә, ашыгыч рәвештә Credit Suisseны сатып алган UBS банкы дүшәмбе көн сәүдәсендә үзе очсызланды: акцияләренең кыйммәте 10,49 процентка төште. Немец банклары һәм иминиятләштерү компанияләре Deutsche Bank һәм Allianz шулай ук очсызланалар, чөнки активларында җимерелгән швейцар банкының облигацияләре байтак. Американың зурлыгы ягыннан 14 нче урында торган First Republic Bankының акцияләре дүшәмбе көнне 44 процентка очсызлангач, алар белән сәүдәне туктаттылар. Дистәләгән АКШ банкы егылып баручы финанс оешмасына ярдәм кулы сузып карадылар – булышмады.

Банклар һәм валюталар ярышып очсызланалар. Төрек хөкүмәтләрендә озак еллар икътисад министры һәм тышкы эшләр министры булып торган Али Бабаҗан телевидениедә туры эфирда кесәсеннән 200 лиралык купюра чыгарды да: «2009 елда бу 134 доллар иде, хәзер – 9 доллар», – диде. Валютасы күпме генә очсызланмасын, Төркия соңгы елларда реаль икътисадны үстерүдә күзгә күренерлек уңышларга ирешә. Пилотсыз техника җитештерү һәм экспортлау буенча дөньякүләм лидерга әверелде, беренчелекне үз кулында ышанычлы тота. Конвейердан төшәргә әзерләнүче бәясе 50–60 мең долларлык төрек электромобилен сатып алу өчен кешеләр чиратка тезелде. Хәтта акчаны алдан түләп куялар.

Соңгы көннәрдә төрек мәгълүмат кырын бор карбиды турында хәбәрләр шаулата. Дүшәмбе көнне Балыкесир шәһәрендә шундый яңа материал җитештерүче завод эшли башлады. Елга мең тонна бор карбиды җитештерәчәк. Тагын бер төрек шәһәрендә куәте 5 мең тоннага җитәчәк янә бер заводны сафка бастыру планлаштырыла. Югары катылыкка ия булган бу материал (корычтан калышмый) сәнәгатьнең барлык тармакларында, аеруча оборона сәнәгатендә кулланыла. Бронежилетлар һәм танк калканнары, двигательләр аңа мохтаҗ. Борның дөнья запаслары Төркиядә тупланган – 73 процентны тәшкил итә. Бор рудасын бор карбидына әйләндерсәң, кыйммәте 300 тапкыр арта, калканлы техника материалы итсәң, 2 мең тапкыр үсә, ракета двигателе җитештерүдә кулланырлык дәрәҗәгә җиткерсәң, 35 мең тапкыр кыйммәтләнә. Төрекләр менә шундый өстәмә кыйммәткә өметләнәләр.

Россиядә

БАЛЫГЫ ТҮГЕЛ, САВЫТЫ КЫЙММӘТЛӘНӘ

Импортны алыштыру һәм санкцияләргә каршы тору юнәлешендә зур көрәш алып барган Россиядә балык консервлары инфляциясе кискен арткан. Скумбрия, сайра консервлары – 20–22 процентка, тунецныкы – 19га, шпрот консервлары 14 процентка кыйммәтләнгән. Консервның үзкыйммәтендә балык үзе түгел, савыты төп урын алып тора икән. Хикмәт шунда: санкцияләр нәтиҗәсендә җиз кыйммәтләнгән, консервның бәясендә савыт белән капкач өлеше 35–37 процентка җиткән. Кибеттән товар сатып алганда, хәзер аның бәясенә карап тормыйбыз, ияләндек, исебез китми. Бары тик картадагы яки янчыктагы акчаның тиз парга әйләнүенә генә гаҗәпләнеп куябыз. Без сизмәгәндә, санкцияләр безнең матди хәлебезне акрын гына кимерәләр. Икътисадчы Николай Кульбака: «2023 ел, мөгаен, Россия икътисадының акрын гына упкынга шуу елы булыр… Шулай да вазгыятьнең тиз начараюын көтәргә кирәкми», – ди. Упкынга төшкәндә, депрессиягә бирелмәс өчен, телевизор карарга була. Анда барысы да ал да гөл.

Рәсми мәгълүматлар алдаша, дип әйтергә җыенмыйбыз. Бары тик берәүләр, стакан яртылаш буш, икенчеләр, яртылаш тулы, дип әйтергә ярата. Икенче позицияне сайласаң, тынычрак яшисең. Росстат бар бит әле. Шул оешма 2022 елда Россия нефтенең үзкыйммәте түбәнәюен әйтә. Беренче кварталда ул тоннага 33,1 мең сум булган, ә дүртенче кварталда 18,6 мең сумга калган. Үзкыйммәтне якынча ике тапкыр киметкәннәр! Шатланмыйча, нишлисең, шатланасың инде. Ватанпәрвәрлек хисләре ташый. Әмма шундый шатлыклы хәбәрнең дә тешне сызлата торган ягы була. Тулаем алганда, Россия нефтенең үзкыйммәте 2012 елдан башлап даими рәвештә үсә. Хәтта ки 2022 елның түбәнгә төшкән 18,6 мең сумлык үзкыйммәте дә 2021 елныкыннан 20 процентка кыйммәтрәк. 2002 ел башында нефтьчеләр «кара алтын»ны чамасыз кыйбатка төшереп чыгарганнар, шул гына. Ел ахырына күрсәткечләр яхшырган, әмма яхшыртылганы да алдагы елныкыннан начаррак килеп чыккан. «Кара алтын»га бәяләр югары торган 2022 елда үзкыйммәт түзәрлек булган. Быел «бәя түшәме»нә бәрелгәч, һәм чималны Көнбатыш куйган чиктән дә арзангарак сата башлагач, үзкыйммәте хәлиткеч факторга әйләнгән. Җитмәсә, транспортлау чыгымнары да кискен үсеп (торбадан түгел, танкерлар белән ташырга туры килә), табыш юкка чыга язган. Тагын бер нәрсә бар: Росстат күрсәткечендә салымнар исәпкә алынмаган. Җир астыннан нефть кудыру чыгымнары гына саналган. Салымнарны да өстәгәч, нефть компанияләренең хәле бер дә сөенерлек түгел, ди шул. Алар яңа проектларны туктатырга, җитештерүне киметергә мәҗбүр булачак. «Не секрет, что ресурсная база России по нефти ухудшается», – ди бу хакта «Российская газета». Күңелне төшермик шулай да. Косервланган балык алганда, балык түгел, савыты кыйммәтләнде, дип уйлагыз. Арзанлы балык ашыйм, дип ышансагыз, кәефегез яхшырыр. Һәрхәлдә, Росстат безгә шулай өйрәтә.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

СЫНМАСКА, СЫГЫЛМАСКА

Мәгълүмати «һөҗүм»гә бирешмәскә! Россиянең Иминлек советы секретаре Николай Патрушев кичә Ульян шәһәрендә узган утырышта шундый бурыч куйды. Утырышта Идел буе төбәгендә иминлекне тәэмин итү турында сөйләштеләр. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Киңәшмәдә Россия җәмгыятенә мәгълүмати һәм идеологик яктан йогынты ясауларга каршы тору, тарихи хәтер һәм традицион рухи кыйммәтләрне саклау, хәзерге мәгълүмат мохитендә Россиянең бәйсезлеген ныгыту мәсьәләләренә аеруча зур игътибар бирелде. Чит илнең махсус хезмәтләре тарафыннан ялган мәгълүмат тарату, терроризм һәм экстремизм кебек тискәре күренешләрне пропагандалауны булдырмауга юнәлдерелгән чаралар да тәкъдим ителде.

– Әлеге мәсьәлә Идел буе төбәгендә генә түгел, бөтен ил күләмендә актуаль. Махсус хәрби операция, интернетның йогынтысы арту, геосәяси киеренкелеккә бәйле рәвештә бүген җәмгыятьтә җитди социаль, сәяси һәм коммуникацион үзгәрешләр бара. Көндәшләребез бөтен көчен мәгълүмат-пропаганда кырында Россиягә каршы көрәш алып баруга юнәлтте. Президент Владимир Путин Россия Эчке эшләр министрлыгының киңәйтелгән утырышында бу хакта искәртеп узган иде. «Каршы якның җәмгыятебезне болгатуны максат иткән теләсә кайсы талпынышын туктатырга кирәк. Күпмилләтле җәмгыятебезнең бердәмлеге элек-электән Россиянең көче булды һәм бүген дә шулай булып кала бирә», – диде ул, – дип билгеләп үтте Патрушев.

Ульян өлкәсе губернаторы Алексей Русских төбәктәге яшьләр арасында да бу юнәлештә зур эш алып барылуын искәртте.

– Ульян өлкәсендә балаларның мәгълүмати куркынычсызлык үзәге эшләп килә. Әлеге үзәк интернет челтәренең балалар сәламәтлегенә, үсешенә һәм куркынычсызлыгына тискәре йогынтысын киметүне күздә тоткан методик, мәгълүмати-аналитик чаралар комплексын булдыру һәм тормышка ашыруны күздә тота. Профилактик чараларга зур игътибар бирелә. Әлеге үзәк укытучыларның да методик базасы булып тора, анда ата-аналар һәм балаларга белем бирелә, яшьләр арасында аңлату эшләре алып бара. Биредә эшләүчеләр үсеп килүче буынга зарарлы булган зыянлы контент һәм мәгълүматларны ачыклау белән дә шөгыльләнә, – дип сөйләде губернатор.

Утырышта халыкның хокукый белемен арттыру турында да сүз булды. Моннан тыш Көнбатыш «һөҗүме»нә каршы торырга ярдәм итүче фәнни һәм социаль проектларны үстерү программаларын эшләргә дә күрсәтмә бирелде.

КЫЙММӘТЛЕ ЮЛ

Илкүләм проект

11 миллиард сум. «Куркынычсыз һәм имин юллар» илкүләм проекты буенча быел Татарстан юлларына әнә шулкадәр акча бүлеп биреләчәк. Ел азагына кадәр республикадагы 31 күперне рәткә китерәчәкләр. Быел кайсы юлларның сыйфаты яхшырачак? Бу сорауга җавап бар.

kzn.ru

Илкүләм проектлар, шул исәптән «Куркынычсыз һәм имин юллар» проекты Россия Президенты Владимир Путин тәкъдиме белән 2019 елдан бирле тормышка ашырыла. Моңа кадәр, 2017–2018 елларда, илнең кайбер төбәкләрендә «Куркынычсыз һәм имин юллар» өстенлекле федераль проекты гамәлдә иде.

– Агымдагы елда Татарстанда юл эшләре программасына барлыгы 48,5 миллиард сум акча каралган. Шул исәптән 32,4 миллиард сум – республика бюджетыннан, 16,1 миллиард сум федераль казнадан бүлеп биреләчәк, – дип сөйләде «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары Артем Чукин. – Республика аша узучы федераль юлларда «М7» трассасын төзекләндерү, Түбән Кама һәм Чаллы юлларын уратып узу юлын салу кебек эшләр дә дәвам иттереләчәк.

Аерым алганда, юл төзелешенә – 3 миллиард, капиталь төзекләндерүгә – 6,6 миллиард, юлларны карап торуга 7,8 миллиард сумга якын акча «түшәячәкләр». Быел «Куркынычсыз һәм имин юллар» проектын тормышка ашыруга 11,2 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк. Шартлы итеп әйтсәк, эш дүрт юнәлештә алып барылачак.

– Казан агломерациясендә 37 чакрым юл төзекләндереләчәк, – диде министр урынбасары. – Шул исәптән Казанның Коләхмәтов, Хәсән Туфан, Ленинград кебек урамнарында 10 чакрымга якын юлны тиешле таләпләргә туры китереп төзекләндерү күздә тотыла. Агломерация эчендәге Казан – Шәмәрдән, Столбище – Атабай кебек төбәк дәрәҗәсендәге юллар да тәртипкә китереләчәк.

Чаллы агломерациясендә «Куркынычсыз һәм имин юллар» проекты кысасында, юл эшләренә 1,4 миллиард сум акча тотылачак, дип фаразлана. Аерым алганда, автокаланың Хәсән Туфан, Вахитов, Сөембикә проспектларын яңартырга җыеналар. Ел азагына Казан һәм Чаллы юлларының норматив торышы 84 процентка җитәргә тиеш. Түбән Кама агломерациясендә әлеге күрсәткеч беразтүбәнрәк – 78 процент. Биредә быел 480 миллион сумлык эш башкарырга ниятлиләр.

Эшнең тагын бер юнәлеше – быел төбәк дәрәҗәсендәге 222 чакрымга якын юл төзекләндереләчәк. Мәсәлән, Азеево – Чирмешән – Шентала, Чистай – Түбән Кама, Апас – Тәтеш юлларында йөрүчеләр җиңел сулап куячак. Биредә юлларны ялт иттерәчәкләр.

Юлчылар күперләрне дә уратып узмый. Ел азагына кадәр республикада 31 күперне рәткә китерәчәкләр. Бу җәһәттән генә дә ике чакрымга якын юл яңартылачак. Аерым алганда, Әлмәт районында Дала Зәе елгасы аша салынган күпердә ремонт эшләре төгәлләнәчәк. Чирмешәндә Зур Чирмешән елгасы аша салынган күпер дә яңа сулыш алачак. Балык Бистәсендә исә Шомбыт елгасы аша салынган күпер яңартылачак.

Ә менә Казанда Вознесение тракты төзелешенә әле шактый акча кирәк. Бу хакта шәһәр башкарма комитетының тышкы төзекләндерү комитеты җитәкчесе урынбасары Эдуард Вафин сөйләде.

– Әлеге төзелешнең беренче чиратында Гвардия урамыннан алып Җиңү проспектына кадәр юл салыначак. 2021–2022 елларда бу эшкә 11,5 миллиард сум акча тотылды. Эшнең беренче чиратын ел азагына кадәр бетерәчәкбез. Юлчылар көннәр бераз корытканны гына көтә. Төзелешнең икенче чиратына килгәндә, аның бәясе 26 миллиард сум тәшкил итә. Былтыр әлеге максаттан 5 миллиард сумлык эш башкарылды, быел 3,5 миллиард сум бүлеп бирелгән. Барлык эшләр дә 2024 ел азагына кадәр тәмамланачак дип көтелә. Тик барысы да финанслауга бәйле, – диде ул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Күренмәс дошман

Татарстанда сөрем газы белән агуланучылар арта. 2019–2020 елларда шундый 30–33 очрак теркәлсә, 2021–2022 елларда бу сан 50гә якынлашкан. Татарстан Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе Сергей Крайнов әйтүенчә, бу әле килеп ирешкән мәгълүматлар гына. Чынлыкта алар тагын да күбрәк.

Сергей Крайнов аңлатуынча, газ кислород җитеп бетмәгән очракта җыела.

– Элеккеге йортларда һава ишекләрдәге һәм тәрәзәләрдәге табигый тишек-тошыклар аша йөри торган иде. Тәрәзәләрне ябыштырган очракта да, һава йөреше яхшы булды. Пластик тәрәзәләр һәм герметик тыгызландырылган ишекләр барлыкка килгәч, вазгыять үзгәрде. Алардан һава бик начар йөри – әгәр тәрәзә һәм ишекләрне япсаң, вентиляция эшләми. Пластик тәрәзәләрне микроҗилләтү режимына кую да фаҗига булдырмый калырга ярдәм итә. Тик, кызганыч, кешеләр үзләре үк гомерләрен куркыныч астына куя, – дип аңлатты белгеч.

Фаҗигаләрнең еш кына кешеләрнең белемсезлеге, битарафлыгы аркасында килеп чыгуына Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Алексей Фролов та басым ясады.

– Быел безнең республикада газга бәйле 24 бәла-каза булды, шуларның 15е –күпкатлы йортларда. Монда яшәүчеләрнең җавапсызлыгы да бар. Татарстанда уңайлы шартларда яшәү өчен мөмкинлекләр күп, ә газ – иң еш һәм күп кулланыла. Шуңа күрә бу мәсьәлә аеруча зур игътибар таләп итә, – диде ул.

Алексей Фролов әйтүенчә, барлык очраклар да белгечләр белән тикшерелә, сәбәпләре ачыклана. Гадәттә алар кеше факторы, эш тәртибен аңлап җиткермәүгә бәйле була. Зурларның җавапсызлыгы аркасында балаларның зыян күрүе – иң аянычлысы.

– Газ колонкалары булган йортлар – иң зур куркыныч тудыра торганы. Шуңа күрә газүткәргеч торбаларны тикшереп торырга, герметиклаштыру кирәк. Әлеге вакытта безнең алда торган төп бурыч – һәр кулланучының газның ничек эшләвен аңлауны тәэмин итү. Газ баллоннары белән аеруча сак булырга кирәклеген кат-кат әйтәбез. Зинһар өчен, игътибарлы булсагыз иде, – диде министр урынбасары.

«Газпромтрансгаз Казан» оешмасының генераль директор урынбасары Михаил Фролов әйтүенчә, республикада ел саен газлаштырылган фатирлар саны арта. Шуның белән бергә бәла-казалар да күбәя.

– Аларның күпчелеге җылыту сезоны вакытына туры килә, – ди ул. – Вентиляция – төтен каналларының төзексезлеге – төп сәбәпләрнең берсе. Икенчесе – көнкүрештә газ куллану тәртибен бозу. Хәтта кайвакыт гап-гади кагыйдәләр дә үтәлми. Әйтик, газ җиһазларыннан кулланганда һава йөреше булырга тиеш. Ягъни тәрәзәне ачып, вентиляция һәм төтен торбаларының тарту көчен даими рәвештә тикшереп торырга кирәк. Әлеге кагыйдәләр үтәлсә, соңгы вакытларда булган бәла-казаларның берсе дә килеп чыкмас иде.

Ел саен техник хезмәт күрсәтү дә газ куллануга бәйле фаҗигаләрне шактыйга киметергә ярдәм итә, дип саный Михаил Фролов.

– Бу уңайдан кулланучыларга мөрәҗәгать итәсе килә. Бар җаваплылыкны тоеп, хезмәткәрләрне өйләрегезгә кертсәгез иде. Бу мәсьәләдә авырлык бар. Һавадагы сөрем газын тикшерә торган система урнаштыруның да нәтиҗәсе бар. Ул чагыштырмача кыйммәт түгел, ә файдасы зур, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Торак-коммуналь хезмәткәрләре урынына йортларга ялганчылар керү очраклары да билгеле. Аларны чын хезмәткәрләрдән ничек аерырга соң?

1. «Газпромтрансгаз Казан» оешмасы хезмәткәрләре һәрвакыт логотип төшерелгән махсус киемнән була.
2. Хезмәткәрләр һәрвакыт үзләре белән таныклык йөртә һәм сораганда берсүзсез күрсәтә.
3. Мәгълүматны тагын да төгәлләштерергә кирәк булса, сайтка кереп, документның номерларын да карарга мөмкин.
4. Шулай ук квитанциядә күрсәтелгән телефон номерына да шалтыратып белешергә була.
5. «Газпромтрансгаз Казан» оешмасы хезмәткәрләре бервакытта да газ җиһазлары сатып йөрми.
6. Хезмәткәрләр бервакытта да үз хезмәтләре өчен кулга акча алмый. Түләү тикшерү узганнан соңгы айда квитанциядә күрсәтелә. Соңгы вакытта QR-код ярдәмендә түләү мөмкинлеге дә каралган.

ТАШЫСА ЕЛГАЛАР ЯРЫННАН…

Яз хәбәрләре

Быел Татарстанда 220 торак пунктка су басу куркынычы яный. 22 күпер, 10 социаль һәм 3 икътисад объекты да судан зыян күрергә мөмкин. Гадәттән тыш хәлләргә каршы тору һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия утырышында язгы ташуга әзерлек турында сөйләштеләр.

Узган ел исә язгы ташу вакытында республиканың 15 районында су басуга бәйле күңелсез хәлләр булган. 3 торак йортка, 179 йорт яны территориясе, 5 күпер, 11 автомобиль юлына су кергән. Татарстан Премьер-министр урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин, бу хәлләр кабатланмасын өчен, бүгеннән үк әзер торырга киңәш итте.

– Көннәр кинәт кенә җылытып җибәрсә, су басарга да мөмкин. Шуңа да һәр район язгы ташуга әзер торырга тиеш. Әгәр инде су баса башлый икән, гадәттән тыш хәл режимына күчү кирәк, – диде Рөстәм Нигъмәтуллин. – Гидротехник корылмаларның торышы канәгатьләнерлек түгел. Су басуга каршы тору өчен, ярларны ныгыту, тирәнлекне арттыру, елга үзәннәрен чистарту буенча чаралар күрергә кирәк. Республика язгы ташуга әзерме? Нинди проблемалар бар? Без моны белеп торырга һәм хәл итәргә тиеш.

Татарстанның гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары Николай Суржко сүзләренә караганда, Казан һәм Лаеш районын су басу куркынычы зур.

– Быел яз ике атнага алдан килә. Март ахыры – апрель башларында су күтәрелергә мөмкин. Ташуга каршы башкарыласы эшләрне бу атна дәвамында тәмамларга дип торабыз. Су биеклеген контрольдә тотучы 35 стационар һәм елга-күлләргә куелган вакытлыча эшләүче 108 су посты бар, – ди ул. – Без су басу куркынычы зур булган районнар белән гел элемтәдә торабыз. Республиканың һәр район вәкилләре белән язгы ташуга әзерләнәбез. Алардагы кимчелекләрне белешәбез, проблемаларын сорыйбыз. Районнарда күперләрнең су астында калуы, машина юлларына су керү, торак-коммуналь хуҗалык объектларына зыян килү борчый. Су чистарткыч корылмаларның төзек булмавы, дөрес эшләмәвенә дә борчыла алар. Шуңа да, ул-бу булганчы, алдан хәстәрен күреп, су басу куркынычы янаган территорияләрнең хуҗаларына аларны иминиятләштерергә киңәш бирәбез.

Очрашуда җыелып торган карны таратырга, аны читкә чыгарырга дигән киңәш тә яңгырады. Гөбенә, Карлы, Кече Чирмешән елгаларында су биеклеге күпьеллык уртача күрсәткечтән югарырак икән. Кече елгаларда кар тыгылу да су басуга китерә. Боз да тыгыла. Республика сулыкларында боз тыгылу куркынычы булган барлыгы 63 участок бар.

Николай Суржко сүзләренә караганда, әнә шуңа да бозны кисә башларга вакыт. Күперләр янәшәсендә боз тыгылса, су басуны көт тә тор. Республиканың 9 районында боз кисү эшенә керешкәннәр инде. Әлегә бозны шартлатмыйлар, әмма гаризалар килә башлаган инде. Бу эшне 19 сулыкны үз эченә алган 14 районда башкарачаклар.

Юллар һәм күперләр турында Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов сөйләде. Аның әйтүенчә, федераль юллардагы күперләрнең 97 проценты чистартылган. Юл буйлары да кардан чистартылып тора. «Дүрт күпер, түбән булу сәбәпле, ел саен су астында кала. Әмма аларны урап узу юллары бар», – ди министр.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча идарәсе башлыгы Рафис Хәбибуллин, юл өзелү аркасында берәү дә зыян күрергә тиеш түгел, дип искәртте.

– Һәр елны күперләр су астында каласын беләбез. Ел саен була торган проблема бу. Әмма без моны белеп торырга, вакытында ярдәм итәргә тиеш. Күпернең аргы ягында калган кешеләргә табиб ярдәме вакытында күрсәтелергә, ризык китерергә, вакытында пенсияләрен алып барып бирергә кирәк. Алар бөтенләй юлсыз калмый. Анда керер өчен ерактан юллар бар, – ди Рафис Хәбибуллин. – Су ел да баса инде ул. Әмма моңа һәркем әзер торсын иде. Синең ишегалдыңа су төшәсен белеп тә, алдан хәстәрен күрмәгәч, ни

Илдар Мөхәммәтҗанов

була инде ул? Коткаручыны гына көтеп ятып булмый. Халык үзен үзе дә кайгыртсын иде. Балыкчыларны гына карагыз әле. Инде бозга керергә ярамый дип торабыз, әмма алар курыкмый. Без бүгеннән сулыкларга 10 коткару посты куйдык, тик мине коткарырлар әле дип, балыкка чыгып китмәсеннәр иде.

Утырышта су басу куркынычы булган район вәкилләре дә үз проблемаларын җиткерде. Питрәч районы башлыгы Илһам Кашапов Мишә елгасы ярларын ныгытуда ярдәм сорады. Нокса елгасы күтәрелеп, Званка һәм Кощаково бистәләренә су керә. Район башлыгына булышырга вәгъдә бирделәр. Чирмешән районының башкарма комитет җитәкчесе Илфат Шәйдуллин гидротехник корылмаларга ремонт кирәклеген җиткерде. Арада 10 ел буе тик торганы да бар икән. Баксаң, анда су да юк икән. Рөстәм Нигъмәтуллин шул гомер кирәк булмаган мондый корылмаларны, хуҗасы булмаган, эшкә ярамаган очракта, исәптән алырга һәм сүтәргә кушты.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БАШ БИРМӘС ТАТАРЛАР

Милләттәшләр

Кострома өлкәсендә яшәүче милләттәшләребез Татарстанга кунакка килеп китте. Бүләк итеп «Кострома татарлары» дип аталган китап-альбом алып килгәннәр. Тәкъдим итү кичәсендә тарихчы Дамир Исхаков аларны образлы итеп «томан артына кереп югала барган» милләттәшләребезнең бер төркеме дип сурәтләде.

Әмма шунысы барыбер шатландыра: томан артына кереп бара кебек тоелса да, югалмаган әле. Өлкә тарихчылары Ренат Абянов белән Марат Сәфәров әнә шундый фаҗига булмасын өчен бар көчләрен куялар. Бу җирләрдә татарлар өч гасыр буена диярлек Идел буена сыенып яшәгән.

Ният кенә кирәк

Барысы да көтелмәгәндә башлана. Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллык бәйрәменә килгән егетләр Болгар каласында очраклы гына тарих фәннәре кандидаты, этнограф Фәридә Шәрифуллина белән очрашалар. Сөйләшеп китәләр. Баксаң, моннан шактый еллар элек, әле студент чагында, диплом эшенә материал җыяр өчен, Фәридә ханым Касыйм татарларының тарихын өйрәнергә барган була. Нииндидер эзлеклелек табып, Кострома өлкәсенә дә килеп чыга.

– Беренче тапкыр Кострома өлкәсендәге Татар бистәсенә килеп чыккач, аралашып китәр өчен «Казан» сүзе пароль булып хезмәт итте, – дип искә ала ул. – Бу сүз ачкыч кебек булды. Башта сак кына караш ташлаган милләттәшләребез шундук кунакка чакыра башладылар, ачылып сөйләштеләр. Мин фотограф Рәшит абыем белән идем. Ул төшерде, мин бистә кешеләренең сөйләгәннәрен язып алдым. Диплом эшем Касыйм татарлары турында булганга, Кострмада яшәүчеләр турында материалларны кирәккә дип түгел, кызыксынып кына җыйдым. Бик озак кул тимичә ятканнар иде. Егетләр белән сөйләшкәч, кызыксынып китеп, инде ничәмә-ничә ел тузан җыеп яткан архивны эшкә җигәргә булдык.

Шул очрашудан соң егетләргә гүя канат куйгандай була. Фәридә ханымның эшен дәвам итеп, алар Татар бистәсендәге халык белән аралашалар, материаллар җыялар, видеоларга төшерәләр, фотосурәтләр ясыйлар.

– Һәр ишекне шакып, өйләренә кереп, сандыкларын ачтырып, ике елга якын мәгълүмат җыеп йөрдек, – ди егетләр. – Ни кызганыч, монда яшәүчеләр телне күптән онытканнар диярлек инде. Бик олы яшьтәгеләр генә аңлый һәм кайбер сүзләрне куллана. Еш әйтелгәннәрен яшьләр дә онытмый, балалар да кабатлый. Без бу китапта шул сүзләрдән төзелгән сүзлекне дә бирдек. Әйе, татарлык бетә бара дип әйтергә мөмкин, әмма, ничек кенә булмасын, монда яшәүчеләр үзләрен, һичшиксез, татар дип саныйлар. Башларына түбәтәй кияләр, мәчеткә йөриләр. Шунысы да бар: Идел буенда төзелгән бу Татар бистәсе күптән инде шәһәр белән тоташкан. Онытылу процессы шуңа күрә дә бик көчле, күрәсең. Гореф-гадәтләрне мәчет ярдәме белән торгызырга тырышабыз. Татар телендә аңламасалар, русча сөйлибез. Үзебездә китапны тәкъдим иткәндә, ник безгә дә кермәдегез, истәлекләребез бик күп иде дип, яныбызга бик күп милләттәшләр килде. Шуңа күрә китапның икенче томы да булыр дип уйлыйбыз әле. Тукталып калмаска исәп. Бу җәһәттән Бөтендөнья татар конгрессының Төбәкчеләр комитеты җитәкчесе Альберт Борһанов та: «Мондый егетләр булганда татар яшәр, китаплар да булыр», – дип, бик матур нәтиҗә ясады.

Бүген Костромадагы татарлар нинди хатирәләр белән яши?

Әюп БУЛАТОВ:
«Безнең йортта 1866 елдан Татар бистәсендә эшләп килгән мәдрәсә шәкертләренең фотосы сакланып калган. Беренче Бөек Ватан сугышы вакытында анда әсирлеккә төшкән төрекләр дә укыткан. Алар өчен җаваплылыкны Кострмада яшәүче татарлар үз өсләренә алган. Төрекләр мәчеткә намазга йөргәннәр, татар гаиләләре белән аралашырга рөхсәт булган, аларның кайберләре бистә зиратында җирләнгән».

Нәкыя ДИНДАРОВА:
«Әти-әни Костромага 1933 елда Чистай районыннан ачлыктан качып килде. Безне бистә кырыендагы баракларга урнаштырдылар. Кайберәүләр дуңгыз абзарларында яшәргә дә мәҗбүр булды. Бердәм булуыбыз гына безне бәла-казалардан коткарып калды. Мин мәҗлесләрне әнием белән әбием өйрәткәнчә үткәрәм. Бәлеш, токмачлы аш пешерәбез. Ашны ләкшә дип атыйбыз. Чәй эчәргә кош теле әзерлибез. Мин бистә татарлары белән бик аралашып яшим. Бөтен милләттәшләрнең телефоны язылган блокнотым да бар».

Татар бистәсе

Костромадагы Татар бистәсенең килеп чыгышы турында берничә фикер яши. Берәүләр аларны татар-монгол токымыннан дип саный. Икенчеләр исә, әсирлеккә төшеп, Романов шәһәрендә яшәгән ногайларның дәвамы дип раслый. Тарих битләреннән күренгәнчә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, халык, тыныч урын эзләп, яшәгән урынын ташлап китә. Шул вакытта күп кенә морзалар да Россия империясенә юл алалар һәм хезмәткә алуларын үтенәләр. Татарларны үзләренә тарту өчен миссионерлар да Урдага юнәлә. Шулай итеп, Россия территориясендә татар бистәләре барлыкка килә. Әмма басым зур булганга, татарларның күбесе христиан динен кабул итәргә мәҗбүр була. Морзаларның күбесе нәкъ шул чорда фамилияләрен русчага алыштыра да инде. Кыенлыклар күрүгә карамастан, ата-бабаларының диненә, гореф-гадәтләренә тугры калганнары да күп була. Күз-колак булырга җиңеләйсен өчен, аларны зур шәһәр тирәләренә урнаштыралар. Кострома янындагы Татар бистәсе дә әнә шул баш бирмәс татарлардан тора дип санала. Аның шулай икәнлеге архив документларында да күрсәтелгән: 1625 елда анда бер төркем татар белән ногай морзасы Урак Тинмаметьев җибәрелә. 1684–1685 елларда Костромага сөргенгә куылган Романов татарларының да исемлеге саклана.

1870–1872 елларда бистәдә 41 йорт була, анда 285 кеше яши. Вакыт узу белән халык саны арта.



Мәчет каршындагы мәдрәсәдә белем бирүче Ариф Сафиуллинга халык борынгы китап-язмаларны китерә.

Кәләшләрне гадәттә Касыйм, Пенза, Түбән Новгород, Казан, Оренбург шәһәрләреннән алып киләләр. Демография кискен төстә үсүгә таба юнәлеш ала. 1924 елгы сан алу буенча анда инде 104 йортта 653 кеше яши.

Халык нигездә игенчелек, балыкчылык белән шөгыльләнә, яшелчә, җиләк-җимеш үстерә. Татарларга хас булганча, күп итеп ат асрыйлар, аларны базарга йөк ташу өчен кулланалар. Кымыз җитештерәләр.

1780 елда бистәдә мәчет торгызалар. Ул төньяк һәм үзәк Идел буенда беренче иман йорты була. 1929 елда, Россиянең барлык төбәкләрендәге кебек үк, Костромада да дингә каршы көрәш башлана. 150 ел нур чәчеп торган мәчет 1930 елда ябыла. Шул ук елның кышында аның манарасын бәреп төшерәләр. Бинадан уку залы, соңрак клуб буларак файдаланалар. 1953 елда ул юкка чыгарыла, җир белән тигезләнә. Бистәдә 1866 елда Казан сәүдәгәре Апаков ярдәме белән мәдрәсә дә төзелгән була. Анда 1917 елга кадәр бушлай белем бирәләр: догалар, китаплар укырга, язарга һәм исәп-хисап ясарга өйрәтәләр. Әмма, документларда язылганча, халык акрынлап рус теленә күчә бара, чөнки бистә үзе дә урыслаша башлый.

Тарихчы егетләр Ренат Абянов белән Марат Сәфәров шунысына сөенә: тел бетеп барган кебек булса да, милләттәшләребезнең саны кимесә дә, Татар бистәсе барыбер сакланып калган әле. Иң мөһиме, Кострома шәһәренең бу өлешендә, һичшиксез, татар рухы яши. Яңа мәчет, элеккеге йортларның бай бизәкләре, хәтта мөселман зираты да бу халәтне баета төшә. Яңа мәчет тирә-якка иман нуры чәчә. Элек мәчет булган, әби-бабайлар озак еллар эшләгән Татпромартель ишегаллары урнашкан урыннарны да бистә халкы изге җир итеп саклый.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Уртак ярдәм

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Хәрби хезмәт вакытында һәлак булган хәрбиләрнең гаилә әгъзалары шәхси торак йортларны төзекләндерү өчен түләү рәсмиләштерә ала. Моннан тыш, аларга торак урыннар буенча түләү чыгымнарын компенсацияләү каралган.

Тагын бер матди ярдәм чарасы – үлгән хәрбиләрнең балаларына ай саен түләнә торган пособие. Ул килешү нигезендә хезмәт итүчеләрнең балаларына бирелә.

Тагын ничек булышалар? Татарстанда махсус операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәмнең өстәмә чаралары каралган. Әйтик, гаиләдә яңа бала туса, аларга махсус кирәк-ярак комплекты бирелә. Мобилизацияләнгәннәрнең 60 һәм 55 яшькә җиткән туганнары (ир-атлар һәм хатын-кызлар) шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин ителә. Өлкәннәргә һәм мөмкинлекләре чикле кешеләргә өйгә килеп бушлай социаль хезмәт күрсәтү каралган. Моңа өстәп, республикада махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның гаиләләренә ярдәмче бирергә турында да карар кабул ителде.

Мәктәп укучылары һәм көндезге бүлектә укучы студентлар бушлай кайнар ризык белән тәэмин ителә. 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балаларга төрле ял оешмаларына юллама бирелә.

Моннан тыш, хәрбиләрнең гаиләләренә йорт хуҗалыгы участогы чикләрендә газ үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау һәм газ җиһазларын сатып алуга 100 мең сумга кадәр субсидия бирелә.

Хәрбиләргә һәм аларның гаиләләренә социаль ярдәм чаралары турында тулырак мәгълүмат белән сайтта танышырга була: **sfr.gov.ru**. Моңа өстәп Социаль фондның Татарстан буенча бүлекчәсенең элемтә үзәгенә шалтыратырга мөмкин: **8-800-1-000-001**.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Сәйдәшев исемендәге авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Сафин** Марат Тәлгать улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, республикада социаль-икътисадый сәясәтне гамәлгә ашыруга лаеклы өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы Дәүләт заказы агентлыгы» акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары **Аксенов** Владимир Ильич; күпьеллык нәтиҗәле фәнни һәм мөгаллимлек эшчәнлеге, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Чаллы институты (филиалы) электр энергетикасы һәм электр техникасы кафедрасы доценты **Әхмәтшин** Роберт Солтан улы; республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүләре, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «ПЕРСПЕКТИВА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гайнуллин** Әнис Котдус улы, «Кама Тамагы гипс руднигы» акционер җәмгыятенең өлкән автомобиль йөртүчесе-экспедиторы **Ермаков** Владимир Сергеевич; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Минханова** Сәкинә Габдрахман кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм юл төзелешен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Күперләр төзү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Мостафаев** Бәһрам Талыб улы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлеге баш киңәшчесе **Трофимова** Айгөл Илгиз кызы; күпьеллык намуслы хезмәте һәм халык сәламәтлеген саклау эшенә зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 5 номерлы онкология бүлекчәсе мөдире – табиб-онкологы **Хәмидуллин** Ринат Габбас улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм илебез машина төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте генераль директорының сатып алулар буенча урынбасары **Ибраһимов** Равил Сәед улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте пресс-рам заводы директорының җитештерү буенча урынбасары **Ломаев** Владимир Ивановичка, «Ремдизель» акционер җәмгыяте двигательләрне һәм агрегатларны капиталь төзекләндерү цехы механика-җыю эшләре слесаре **Мирзаянов** Илгиз Нурлыгаян улына, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте двигательләр заводының автомат линияләр һәм агрегат станокларын көйләүчесе **Чухно** Вячеслав Анатольевичка, «Радиоприбор» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – производство буенча директоры **Потапов** Вячеслав Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Олеокам» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Горшков** Сергей Петровичка **«Татарстан Республикасының атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАТНАШ УРМАН ӘЧЛӘРЕНДӘ – ИМӘНЛЕК

Уйлану

Сүземне Аяз Гыйләҗевкә кагылышлы фикерләрдән башлыйммы яисә Нурания Мөхәммәтхан кызы Җамалиның киң колачлы эшчәнлегенә соклану хисләремне яктыртуга багышлыйммы икән соң дип баш ватып утырудан башларга булдым. Дөрестән дә шулай... Кайсы юнәлешкә карата күңелемдәгесен әйтеп бетерергә алынырга ниятләсәм дә, максатыма ирешә алмаячагымны чамалыйм. Алай да, Аяз Гыйләҗев турында нинди яңа фикер әйтә алам соң мин, Нуранияга кагылышлы берәр җылы сүз әйтүем фидакарьләрчә булыр дигән уйга килдем.

Быелның 17 гыйнварында Аязымның дөньяга аваз салуына 95 ел булды. Бу датаны кемнәрдер билгеләп үтәргә теләмәсәләр дә, күпчелек аны искә алырга лаеклы ел хисабы итеп исәпли. Минем өчен Аязыма карата шундый мөнәсәбәтне күзәтү аеруча авыр булды. Татарлыктагы тарлыкмы бу? Аңламассың! Хәтерем ялгышмаса, Әмирхан ага Еникинең (1909–2000) вафатыннан соң 95 еллыгын Башкортстанда уздырганнар иде, ә Татарстан өчен аңа игътибар итеп тору кирәк табылмады. Үзе юкның күзе юк... Аязның Башкортстаны юк шул! Нишләмәк кирәк! Шушындый авыр кимсетелүләрне уйлый-уйлый, катты китте башларым. Без кая барабыз?! Аяз гомере буена «Совет әдәбияты» – «Казан утлары» журналына яздырулар вакытларында татарлар яшәгән төрле төбәкләргә үз хисабына чыгып китеп, шушы матбугат чыганагына язылучылар санын арттырырга тырышып яшәде. Гомере буена шушы матбугат битләренә тәкъдим ителгән әсәрләрне өйгә алып кайтып, укып, үзенең тәкъдимнәрен яза торды. Аңа берәү дә бу эшне башкару вазыйфасына таләп куймады. Бушлай башкарган хезмәте иде ул аның, намусы кушканга эшләнгән гамәле.

Уйлап-уйлап карыйм да «90 (2018) еллыгында Язучылар берлеге игътибар иттеме соң?» – дигән сорауны куям. Анда да Г. Камал театры белән Радик Бариев режиссерлыгында башкарып чыккан юбилей уздырылды шул. Язучылар берлеге шылт та итмәде анда. Ә бит Аяз драматурглар белән алны-ялны белмичә эшләгән зат иде. Ул Туфан Миңнуллин, Рөстәм Мингалим, Ризван Хәмид белән чын дусларча театр сәнгатен җанландырырга тырышып яшәде. Мактардайны мактап, сүгәрдәйне сүгеп яшәде шул – холкы үзе белән булды...

Ә хәзер инде әйтәсе килгән төп фикеремә сүз бирим, язганнарым картлык хисләремнең дуамаллыгы микән? Үземнең усаллыгым белән казынып чыгарылган күңелем төшенкелеге микән?

Нурания Мөхәммәтхан кызы (Аяз холкындагы бер бала) 2–3 еллар дәвамында инде Аяз Гыйләҗевкә багышлап фестиваль уздырасы иде дигән ният белән янып йөрде. Ул – аның идеясе, проект авторы. Фестиваль төпле фикерле бер оештыручы булмаганда барып чыга торган гамәл түгел.

Нурания, җиң сызганып, Аяз Гыйләҗев иҗатын мәгънәви тирәнлегенә төшеп, яңадан өйрәнә. Әсәрләрен кат-кат укый. Минем өйгә дә килеп, Аязның үткәне белән кызыксына. Аязның әсәрләрен укыгач, сораулары туа: «Нәкыя апа, «Урамнар артында яшел болын»ын укып чыктым, ай-һай, шәп әсәр. Ни өчен телдә гел Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев актив кулланылышта түгел?» Җавабым: «Аяз үзе башлап җибәргән кулланылыш ул. Аязның чыгышларында, язмаларында гел шулай булды. Аяз аларның иҗатын үрнәк итеп күрсәтүдә ялгышмады. Ә Аяз совет системасына каршы фикердә булып яшәве белән әзрәк читкә тибәрелеп кала бирде. Ә алар өчесе өч стильдә яза торган чын ихтирамга лаеклы каләм ияләре бит. Аязның иң якын дусларыннан Шәүкәт Галиевның болай әйткәнен хәтерлим. «Аяз, гел янәшәңдәгеләрне мактап йөреп, үзеңне түбәнәйтәсең бит син», – дигән иде. Син шуны тоеп алгансың икән! Фразеологик сүзлекләрне генә кара, анда Аяз теленең үрнәкләре күпчелек. Бу турыда да матбугатта бер сүз әйткән кеше юк. Аязның вафатыннан соң байтак вакыт узгач, «Казан утлары»нда гомере буена әдәби бүлек мөдире булып эшләгән Рәфикъ Юнысов шалтыратты: «Ай-һай, шәп әсәр укыдым. «Урамнар артында яшел болын», – дигән иде. Нурания, син ялгышмыйсың...» – дидем.

Ниһаять, тәвәккәлләп, гыйнвар айларында Нурания хыялын тормышка ашырырга ниятләп, Казан шәһәре күләмендәге мәгариф идарәсенә мөрәҗәгать итте. Нәтиҗәдә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты мәгариф идарәсе, Казан шәһәренең «Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл күптелле мәгариф комплексы» дәүләт автономияле гомуми белем учреждениесе, Казан шәһәре Совет районының «Дәрвишләр бистәсе балалар иҗат үзәге» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе берләшеп, Нуранияның идеясе буенча эш башлый. Фестиваль-конкурста Казан шәһәре белем бирү оешмаларының 7–11 сыйныф укучылары һәм укытучылары катнашты.

Бу фестиваль «Адымнар»да узды. Фестиваль кысасында меңләгән укучының күңеленә Аяз Гыйләҗев иҗатына җылы мөнәсәбәт уятылды. Алар чәчмә әсәрләрен өйрәнеп, рәсемнәр ясадылар, тәрҗемә итү тәҗрибәләре уздырдылар, әсәрләренә карата фикерләрен язарга өйрәтелделәр. Шушы киң колачлы эштә меңнәрчә укучы катнашып, үзара конкурслар уздырылып, сайлап алынганнары фестивальгә үк җиңүчеләр булып килеп җитте. 89 укучы-җиңүчегә дәрәҗәле дипломнар тапшырылды. Фестивальнең икенче өлешендә – зур залда сәхнәдән яңгыраган иҗади өлеш тамашачыларны нык сөендерде дип уйлыйм. Фестивальдә Камал театрыннан «Яра» әсәре кузгатылып, Фәнис Җиһанша һәм Ләйсән Рәхимова уйнаган Зәйтүнә һәм Габдуллаҗан образларының яңартылып җанландырылуы, аның узгандагы шаулап барган елларын искә төшерде. «Җомга көн кич белән» әсәреннән Гайшә кабере каршында Бибинур образы итеп сурәтләнгән монологны К. Тинчурин исемендәге театрдан Әлфия Хәсәнова сөйләп тамашачыларның күңелен нечкәртте.

Камал театрыннан Фәннүр Мөхәммәтҗанов «Йәгез, бер дога!»дан өзекне гайрәтле укуы белән сокландырды. Тинчурин театрыннан «Өч аршын җир»дәге Мирвәли монологын Ирек Хафизов оста итеп халыкка җиткерде. Ерак Чаллыдан Аяз Гыйләҗев исемендәге театр артистлары «Болан» спектакленнән өзекләре белән тамашачыда аның иҗатына карата кызыксыну уяткандыр. Әтнә театры артистлары «Кар астында кайнар чишмә»дән өзекләр күрсәтеп, Аяз иҗатындагы төрлелеккә бер адым ясады. Айгөл Хәйри Аязымны зурлап, улым Мансурның «Бичура»сындагы «Сагышлы җыр»ны җырлап, мине еларга мәҗбүр итте. Сибгат Хәким сүзләренә Рөстәм Яхин көй язган «Безнең таныш өянкеләр»не, Аяз яраткан җыр дип, Нурания җырлаучыларны эзли башлаган. Гомерләр үтә икән шул! Вафирә, Рафаэль Сәхәбиев мәңгелекләренә күчкәннәр! Нуранияга яшьләрдән шул җырны өйрәтергә алыну хәстәренә керешергә үк туры килгән. Ул җырны башкарган «Адымнар» мәктәбендәге музыка укытучысы Тамчыгөл Камаевага рәхмәт яусын! Шул җыры белән ул кызга зур сәхнәләрдә озак-озак еллар дәвамында чыгышлар ясау насыйп булсын! «Әтәч менгән читәнгә» әсәрен укыган 13 нче татар гимназиясенең җиденче сыйныф укучысы, җитәкчесе Алинә Сәгәрәева тарафыннан әзерләнгән Розалина Николаеваның хәтер сәләтенең шаккаткыч булуына хәйраннар калдым. «Җомга көн кич белән» әсәреннән өзекне «Адымнар» мәктәбенең 8 нче сыйныф укучысы Нурия Хөсәенова (укытучысы – Раилә Хөснетдинова) тамашачының күңелендә миһербанлылык уятырлык итеп башкара алды. «Әгәр бик сагынсаң» пьесасына да мөрәҗәгать итеп, Әсфан белән Фәүзия арасындагы мәхәббәт маҗараларына тотына алган балалар бар икәнлеген күрү мине нык куандырды. Алар 16 нчы татар гимназиясе укучылары – Рәсүл Хәбибрахманов белән Әминә Сәмигуллина икән, җитәкчеләре – Роза Ибәтова. Шушы тамашаларны залдагы тамашачыларга оста итеп тапшыра алган Ришат Әхмәдуллинга ничек кенә түбәнчелек белән баш имисең?!

Нурания Җамалинең режиссерлык сәләтенә хәйран калып, аңа мең-мең рәхмәтләремне җиткерәсем килде. «Кеше колачы киңлеге үз кысасына сыйдыра алмаслык фикри хезмәтне кем бәяләргә тиеш икән?» – дигән сорауны үз-үземә куеп, баш ватам. Аңа карата сүз белән генә әйтеп, күңелемнең ничек ләззәтле хисләнгәнен аңлатып бирә алырмынмы соң мин? Юктыр!

Татарлар яшәгән һәр төбәк Нурания Җамали белән Ходайның һәрбер бирмеш көнендә очрашып яши ич. «Адымнар» мәктәбе комплексына урнашканга кадәр ул бит гомере буена телевизион сериаллар эшләү белән мәшгуль булды. Ай-һай, ул төшергән фильмнарның күплеген, аларның мәгънәви, тәрбияви әһәмиятен мин сүзләр белән генә әйтеп бетерә алырмын микән?! Минем андый бәяләмә табарлык сүз кодрәтем юк. Инде ике меңенче еллар башында ук ул төшергән фильмнарны, кабатлап-кабатлап, «ТНВ» каналы аша һәркөн күрсәтеп торалар. Шулай булгач, ул татарның миллионлаган халкын татар теленә мәхәббәт хисләре аша тәрбияли бит. Җитмәсә, «Адымнар»да ел саен укытучылар коллективыннан артистлар әзерләп, спектакльләр дә куярга алына бит әле ул. Хәзер Т. Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» спектакле репетицияләре бара. Хикмәти кодрәт иясе түгелме бу хатын?! Мин ялгышмыймдыр дип уйлап, сүземне йомгаклыйм.

Нәкыя ГЫЙЛӘҖЕВА

Авыл язмалары

Марат КӘБИРОВ

Гомерне кыскартучы

Әгәр дөньяда синең тормышыңны катлауландырырга сәләтле булган кечкенә бер мөмкинлек бар икән, ул мотлак хәрәкәткә киләчәк. Котылгысыз рәвештә. Зур проблемаларны хәл итү, әлбәттә, үзеңне зур итеп тоярга ярдәмләшә, ләкин теге кечкенә җитешсезлектән үз вакытында котыла алсаң, гомереңнең зур өлеше үзеңә калачак.

Тәмәке тартудан мин котыла алмадым инде... Кемнеңдер иҗатын яратучылар, гадәттә, аңа охшарга тырышып, шул кешенең җитешсезлекләрен кабатларга әвәс була. Хәйям «мәйләп» алырга яраткан дип хәмергә тартылучыларны үземнең дә очратканым бар. Марк Твенның төребкә кабып төшкән сурәтләре дә күпләрне тәтен суырырга этәрә. Тик бер нәрсә бар: дөньяда миллионлаган алкаш һәм тәмәкеник бар, ә шагыйрь һәм фәйләсүф Хәйям, кабатланмас сатирик Марк Твен һәркайсы берәү генә. Әгәр минем дә иҗатны яратучылар бар икән, колагыгызга киртеп куегыз – сезгә тәмәке тартырга ярамый. Бу дөньяда хет сез миннән әйбәтрәк булырга тиешсез. Тәмәке – ул яхшы нәрсә түгел, үзе зарарлы, үзе вакытны ала, үзе кыйбат. Мин, мәсәлән, ай саен бер кредит түләрлек акчаны шуңа әрәм итәм. Әле менә тагын бер мәшәкате килеп чыкты...

Тәмәке тарткан кешенең проблемасы акча белән сәламәтлек кенә түгел әле ул. Бер урынга җыеп барырга гадәтләнмәсәң, бөтен дөнья тәмәке төпчеге белән тула. Ыргытканда җайлы булса да, җыелып киткәч, ул бөтен дөньяны ямьсезләп ята. Чүп бит инде. Хәтта гади чүп кенә дә түгел, ә синең кимчелекләреңне бөтен кешегә сөйләп ятучы астыртын нәрсә. «Бу – үз теләкләрен чикли белми торган ихтыярсыз бәндә, – ди ул ихатаңа килеп кергән һәрбер затка. – Начар гадәтләрен – ташлый, яхшы гадәтләрне үзләштерә алмый торган адәм актыгы. Чисталыкның, пөхтәлекнең ни икәнен дә белми, әнә бит бөтен ишегалдын шапшаклап бетерде. Тыштан гына әйбәт булып күренә ул, ә асылда... Хәер, үзегез дә күреп торасыз инде...» Ә кергән кеше үзе дә күреп тора. Сукыр түгел ич.

Җәй көне әле ул төпчекләрне бер генә урынга җыярга күнегә башлыйсың. Өйрәнеп кенә беттем дигәндә, кыш җитә, кар ява. Кар яугач, рәхәт бит, кайда туры килә, шунда төртәсең дә китәсең, күренеп ятмас өчен кар белән каплап куясың. Капларга онытсаң, яңа яуганы күмеп китә. Менә шундый рәхәт тормышка ияләнеп кенә җиткәндә, яз җилләре исә башлый. Кояш көлә, кар эри, төпчекләр чыга...

Менә шундый мәшәкатьтән котылам дип, быел төпчекләрне кыш буена бер генә урынга җыеп бардым. Тәртипсез иркенлеккә бер өйрәнгәч, тәртәгә керү бик җайлы гына түгел ул. Кайчагында гадәт буенча карга гына чиртеп җибәрәсең. Шуннан кире чокып алып, кирәкле җиргә илтеп салырга туры килә. Тагын әллә нинди мәшәкатьләре бар. Тик мин барысын да җиренә җиткереп үтәргә тырыштым. Сөендем инде үземнең шундый тәртипле була алуыма. Кыш буена хәтсез җыела икән. Берничә чиләк сыешлы зур мичкә тула язды. Шуңа караган саен, мин үз-үземне тәртиптә тота алуыма шатландым.

Быел безнең якта кисәк эретте. Берничә көн рәттән кар яуды да кинәт җылытып җибәрде. Кояш гашыйк булган кебек кайнарланды. Аннан соң кар кисә торган җилләр хакимлеге башланды. Ул җилләр вакыты белән бик көчәеп китте. Табигатьнең шундый процедураларыннан соң, берничә көн эчендә кар эреп бетә язды, бөтен тирәяк су астында калды. Әнә шундый җил-яңгырлы бер төнне уздыргач, иртән чыгып карасам, ишегалдын баскан су өсте тәмәке төпчекләре белән тулган. Җил теге мичкәне аударган да эчендәге бөтен байлыгын яңгыр юып төшергән икән...

Дөресен генә әйткәндә, мондый мөмкинлекне мин беркадәр күз алдына китергән идем, тик әлегә иртәрәк дип ышык урынга кертми калдырдым. Соңрак онытылды.

Әле менә көне буена ихата буйлап сибелгән төпчекләрне җыеп йөрдем. Көн буена! Бер кыш эчендә тәмәке минем гомерне төп-төгәл бер көнгә кыскартты. Вәт менә шул. Әгәр дөньяда синең тормышыңны катлауландырырга сәләтле булган кечкенә бер мөмкинлек бар икән, ул мотлак хәрәкәткә киләчәк.

Менә бу урында минем һәр укучыма сабак бирерлек нининдидер акыллы сүз әйтәсем килә. Тик булдыра алмыйм. Килеп чыкмый. Шулкадәр сантыйлык кылганнан соң акыллы сүз әйтү мөмкин түгел. Бәлки, кирәкмидер дә. Бу дөньяда һәр очракта да акыллы булу зарур түгел, кайчагында ахмаклыктан ераграк тору да җитә.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация:

– о структуре и объеме затрат на производство и реализацию товаров (работ, услуг) ООО «Альтернативная энергосбытовая компания»;

– об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

ӘМИРНЕҢ СТЭНЛИГА ЮЛЫ

Әмир Шакировның шәхси архивыннан

Танылу

Кышкы елларда Балтачта район газетасы призына үткән хоккей ярышлары 18 яшьлек Әмир Шакировны бөтен татар дөньясына танытты. Смәел авылы командасы составында уйнаган егет турында редакция үз сайтында: «Ярышларда чит ил командаларында чыныгу алган райондашыбыз да катнашты», – дип кыска гына белешмә бирә. Алардан күреп алган бик күп мәгълүмат чаралары Смәел егете турында бер-берсе белән узыша-узыша язды.

«Ничек моңа кадәр бу егет турында бер дә ишетелмәгән икән, укытучылары да берни әйтмәде», – дип уйлаган идем. Баксаң, Әмир Казанда туып-үскән, шунда белем алган, физкультура-спорт көллиятен тәмамлаган икән. Әтисе Илнур белән сөйләшүне дә шуннан башладык.

:: Бөтенесе Әмирне Балтач егете, Смәел егете дип язды, бу ялгыш каян киткән соң?

– Ялгыш түгел ул. Дөресе шулай. Әнисе белән без дә, Әмир дә үзебезне авылныкы дип саныйбыз. Туган авылым Смәелдә өй салдык, тормыш иптәшем Эльвира – күрше Ор авылыннан. Чепьяда шәхси эшем бар, авылга эзне суыткан юк. Әмир дә бала чактан шунда үсте, әле дә бөтен ялларын, каникулларын шунда үткәрә. Кайткан чакларында ярышларга туры килсә, әле дә авыл, район командасы өчен уйный. Мин үзем дә – бала чактан хоккей дип җан аткан, райондагы бихисап ярышларда катнашкан кеше. 2013 елда төнге хоккей лигасы вакытында Балтач командасы белән Сочига кадәр ярышларга бардык. Әле дә районның ветераннар командасында уйныйм. Аерым ветераннар лигасы бар, алты команда ел саен көч сынашабыз.

:: Әмирнең хоккей белән кызыксынуы да тикмәгә генә булмаган, димәк.

– Әйе, хоккей безнең канда дисәң дә була, без өч ир туган, өчебез дә хоккейны бик яратабыз. Әмирне биш яшендә «Ак барс»ның балалар клубына бирдек. Биш төркемдә бик күп бала шөгыльләнә иде. Башта алар бик кызыксынып йөри, тора-бара сирәгәяләр, яратып, теләп йөрүчеләр генә кала. 11 яшендә инде ике генә төркем иде. Әле бит без аны 9 яшеннән Сабага боз сараена да йөрттек. Андагы «Тимерхан» командасы өчен чыгыш ясады. Әйбәт уйнады, үзеннән зурраклар белән бер командада булды. Шул еллардан ул бик каты режимда яшәде: иртә ята, иртә тора. Әйтик, кичке алтыда инде ул йокларга ята иде. Организмына көч килмәсен өчен, без аны кимендә ун сәгать йокларга тиеш дип санадык. Иртәнге алтыда күнегүләре башланса, ул инде биштә яхшы кәеф белән бозга чыккан була иде. Мәктәптә укулары сәгать бердә бетә, мин аны мәктәп янында көтеп торам һәм Сабага тренировкага китә идек. Мәктәп киемнәрен машинада гына алыштыра, әнисе контейнерлар белән җибәргән ризыкны машинада гына ашый иде.

:: Бала өчен шактый киеренке режим бит. Арыган, туйган чаклары да булгандыр...

– Юк, ул беркайчан булды, җитте, туйдым, бармыйм, димәде. Дөресен әйткәндә, кайчакта бу ыгы-зыгыдан үзебез арый идек. Әнисе белән әле дә сөйләшәбез: тагын бер улыбыз булса, без аның белән бу юлны үтә алмаган булыр идек инде, дибез. Дөрес аңлагыз, без аны беркайчан, бернәрсә дип тә мәҗбүр итмәдек. Ул үзе шулай теләде. Мин инде аны җиде яшендә беренче тапкыр Чаллыда, 9 яшендә Чиләбедә өчәр атнага хоккей буенча лагерьларда калдырып кайттым. Чит-ятлар арасында берүзен! Ул әнә шул авырлыклар аша да мөстәкыйльлеккә өйрәнгәндер. Унике-унөч яшендә инде ул мондый җыеннарга үзе әзерләнеп чыгып китә иде.

> Аның юк-бар турында уйларга, юк-бар белән шөгыльләнергә беркайчан буш вакыты калмады. Үзе теләмәсә, аны беребез дә мәҗбүр итә алмас идек. Рәхмәт, әнисе дә кичерешләрен сиздермәде, күрсәтмәде. Хәзер бит элемтә заманы, элекке кебек, нишли икән, дип кайгырып торасы түгел.

:: Шуңа да чит илдә ияләнү чорын җиңел кичергәндер?

– Ул аның хыялы иде бит. Кече яшьтән шуның өчен инглиз телен тырышып өйрәнде, шөкер, юлында бу хыялын тормышка ашырырга ярдәм итүче кеше дә очрады. Унбер яшьтә «Ак барс»та ике төркемгә калгач, Әмир икенче тренерга туры килде. Тренеры Артем Олегович Лагутин «Смена» командасына күчкәч, Әмир дә шунда күчте. Остазы Әмирнең шәхес буларак формалашуында да, чит ил клубында уйнарлык дәрәҗәгә ирешүендә, анда китүендә дә 80–90 процент роль уйнады. Үзе дә яшьлегендә чит ил командасында уйнаганга, ул аңа әлеге клубларга юлны ачты да инде. Әмма бөтенесе дә җайлы гына бара алмый. Әмиргә дә виза алу шактый проблемалы булды. Анысы артыннан да бер ялгызы йөрде. Башта вакциналар белән проблема чыкты, аннан Сараеводагы консуллыкта виза бирүдән баш тарттылар. Әмир тиз генә бирешә торганнардан түгел, виза алыр өчен Варшавага китте. Андагы консул да «юк» дигәч, улыбыз аңа: «Сез минем хыялны үтердегез», – дигән. Ә ул улыбызга яңадан бер пакет документлар алып килергә кушкан. Шулай итеп, өченче талпынудан виза алды һәм 18 яше тулган көнне АКШка очты, туган көнен самолетта каршы алды.

:: Чит илдә Әмир нинди шартларда яши?

– Ул бүген Лос-Анджелес янындагы Онтарио шәһәрендә яши. Ел әйләнәсе плюс 20 градус, 20 чакрымда гына Тын океан... Клуб белән килешү бер елга төзелә, яшьләр лигасында 21 яшькә кадәр уйный ала. Алга таба ничек булыр, анысын белмибез инде. Әлегә аларга хезмәт хакы түләнми, әмма җиңүләр өчен бонуслар, безнеңчә премияләр бирелә. Юл чыгымнарын үзебез күтәрәбез, ашау-яшәү – тулысы белән клуб карамагында. Анда тәртип шундый: яшүсмерләрне аерым гаиләләрдә яшәтәләр. Ашауны да әлеге хуҗалар әзерли. Ә инде үзебезнең ризыкларны сагынса, Әмир үзе дә пешереп ашый, ул анысын да булдыра. Шулай да өйгә кайтканда, әнисе аны ул яраткан токмачлы аш һәм өчпочмаклар пешереп көтеп тора.

:: Уенчы буларак үзенчәлеге нидә?

– Ул сакчы буларак та, һөҗүмче буларак та бердәй тигез уйный. Мондый уенчыга командада уңышка ирешү җиңелрәк. Хәзер уйный торган «Онтарио Рейн» яшьләр командасында аның баллары начар түгел. Беренче звеноларда уйный, уртача һәр уенда 0,66 балл җыя. Озын буйлы, нык гәүдәле булуы да (189 см) өстенлек бирә. Үз дивизионнарында икенче урынга чыгып, алар 6 марттан плей-офф уеннарын башлый. Бездән аермалы буларак, анда дивизионнар да, командалар да күп.

:: Улыгызның уеннарын карап барасызмы, киңәшләр бирәсезме?

– Сәгать аермасы зур булу сәбәпле, бөтен уеннарын да турыдан-туры карыйм дип әйтә алмыйм, әмма язмада бер генә уенын да карамыйча калдырмыйм. Киңәш биргән, үземчә анализ ясаган булам инде, ул ялгышларын үзе дә бик әйбәт белә.

:: Стэнли Кубогы Әмирнең балачактан иң зур хыялы икән...

– Аңа ирешү өчен, биш баскыч үтәргә кирәк. Әмир – шуның өченчесендә. Нәтиҗәнең нинди булачагы улымның үзеннән, холкыннан тора, дип уйлыйм.

:: Бер көн килеп, Әмирне «Ак барс»ка чакырсалар, кайтыр идеме?

– Ул турыда сөйләшкән юк әле. Улыбыз – гап-гади бер уенчы бит. Әлегә әллә нинди уңышлары да юк. Мәгълүмат чаралары гына аннан «йолдыз» ясарга тырыша.

Әңгәмәдәш – Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

СӘНГАТЬЛЕ СӘГАТЬ

Шөгыль

Казанның Вознесение бистәсендә яшәүче алтын куллы Илфат Әхмәтгалиев белән башта телефон аша гына сөйләшмәкче идек, тик ул сүзне кыска тотты: эшләремне килеп күрмичә, берни сөйләмим! Без килүне көткәннәр. Өйләрендә тәртип, чисталык, табын түрендә – бәлеш, хатыны Сәриянең өстендә – милли күлмәк. Бер-берсен яратулары күзләреннән күренә. Сәриянең ирен хөрмәт итүе, Илфатның исә сөйгәнен кадерләп яшәвен аңлап алдык.

– Без дүрт малай үстек. Әти, мәрхүм, барыбызны да эшкә өйрәтте. Бездә тик утырырга ярамады. Әти гомере буе машина йөртте, кулы алтын иде. Белмәгән бер эше булмады. Өч абыем да эшкә хирыс. Авылда яшәүче Илдар абыем тракторга кадәр үзе ясады. Түбәндә яшәүче Илдус һәм Котдус абыемнар да бик осталар, – дип сөйли гаилә башлыгы.

Илфат та машина йөртүчегә укый. Аннары кранда эшләргә өйрәнә. Кыскасы, техника җене кагылган аңа. Илдар абыйсы белән очрашсалар, нинди яңа төр трактор ясарга, дип баш ваталар икән. Абыйсы солдат шинеленнән бияләйләр теккән. Авылда ничәмә-ничә кешегә антенналар ясап биргән. Абыйларының осталыгын күреп торган Илфат баштарак үзендә сәләт булмаганга читенсенә дә. Осталыгы эшли башлагач ачыла. Хатыны, балага мәктәптән җимлек ясарга кушканнар, диюе була, Илфат, ничек матур итеп ясарга икән, дип баш вата башлый. Башта 5 литрлы полиэтилен шешәне генә кисеп куймакчы була. Әмма шунда әтисенең сүзләре исенә төшә: «Эшләгән эшең башкаларныкыннан бер киртек өстен булсын!»

Илфат эшкә тотына. Материалын юнәтә дә бер дигән җимлек ясап куя. Икенче юлы алар улы белән бер бәйгедә катнашыр өчен сәгать ясыйлар. Карап торышка бик күркәм килеп чыга бу эш. Илфатка шул җитә! Ишегалдындагы агач ботакларын да әрәм итми, аларны эшкәртеп, кискәләп куя. Танышлары, миләш, шомырт, юкә, алмагач ботагы янына артышныкын да кушып җибәр, дип киңәш бирә. Ә артышның хуш исе! Илфат бар фантазиясен эшкә җигеп, сәгатьләр ясый башлый. Нинди генә төрләре юк аларның!

Авылындагы мәчеткә догалар язылганын бүләк иткән.

– Сәгатьләрнең механизмын, саннарын һәм укларын сатып алам. Калганын үзем эшлим. Башта түгәрәк әзерлим. Шул түгәрәккә матур ботаклардан кисеп алынган вак кыйпылчыкларны тезәм. Шуларны ябыштырып утырам. Сабырлык сорый торган эш. Әмма миндә анысы җитәрлек, – ди Илфат.

Менә шушы урында аның күзләре яшьләнә. Гомер юлы җиңел генә бармый аның. Аякка басар, кеше булыр өчен күп тырыша. Күбрәк читкә китеп эшли. Тундрада өшеп, буранда адашып, ач утырган чаклары да була. Бервакыт салкын тиеп нык авырый. Шунда клиник үлем дә кичерә. Табиблар, үлде, дигән була. Аңын җуйгач, әнисе җитәкләп алып киткән була. Сыйныфташ кызы килеп, туктатып кала үзен. Илфат исә шәфкать туташының битенә сукканыннан айнып китә. Читтә эшләү җиңел булмаса да, ул җирләрне тагын бер күрергә хыяллана Илфат.

– Без элек эшләп үстек. Мәктәптә хезмәт дәресләре бар иде. Укытучыбыз Наил абый эшне яраттыра белде. «Булдыра алмыйсың» дигән сүзне белмәде, гел үсендереп торды. Их, менә хәзерге балаларны кызганам мин! Үзебез өч бала үстерәбез. Олы улымның агач эшенә исе китми. Кызым әзрәк кул арасына керә әле. Кечкенә улымны да эшкә өйрәтү җиңел түгел. Телефон үз эшен эшли. Әгәр агач эшенә тотынмасам, мин дә интернет колы булыр идем инде. Телефоннан туеп, остаханәмә чыгып китәм, – ди ул.

Ә остаханәдә ни генә юк! Балалары үскән бишек тә үз куллары белән ясалган. Аны оныкларга дип саклап торалар. Стенада картиналарның агачтан эшләнгәннәре дә, минераль су шешәсе ватыкларыннан ясалганнары да бар. Әтисе ядкәре итеп саклаучы кәнәфи дә бар әле. Барысына да ярату, кул җылысы кергән аларның. Сәгатьләрнең исә ниндие генә юк! Күбесен ошатып алып китәләр икән. Теләгәннәрен әйтеп, заказга эшләтүчеләр дә бар. Илфатның кул эшенә бик вакыты җитми. Көндезләрен Казанны биеклектән күзәтә ул. Кранда эшли. Йортлар төзи. Өенә кайткач, арыганлыгын җиңеп, яраткан эшенә тотына.

– Хыял белән яшим. Күңел авылга тарта. Балтач районының Арбор авылында туып-үскән кеше мин. Пенсиягә чыккач, Сәрия белән шунда кайтып төпләнербез, дип торабыз. Мәктәп укучылары белән түгәрәкләрдә шөгыльләнер идем. Сабыйларны кечкенәдән кул эшенә өйрәтеп үстерәсем килә. Элек бит без бар эшкә мәктәптә өйрәндек. Югары классларда тракторга укыттылар. Шул белем әле дә сынатмый, – ди ул.

Илфатның хыяллары күп. Арборда балалар өчен картинг үзәге дә ачасы килә. Атта йөрергә өйрәтергә дә хыяллана. Туган якка чакырып торучы агачлары бар аның. Әтисе, Илдар абыйсы белән алар нефтьүткәргеч салыр өчен кисеп ташланган урманны яңадан торгызалар. 8 гектар җирдә үсүче нарат, чыршыларны күз карасы кебек саклый ул. Әтиләре истәлеге!

– Әтиемә хөрмәтем зур минем. Чын ир итеп үстерде. Бер генә әйтер иде. Абыйларны тәрбияләгәнен күреп, мин артык тәртипсезләнмәдем. Тәмәке тартмадым, аракы эчмәдем, кәрт сукмадым. Без үскәндә матчада сыек тал чыбыгы торыр иде. Шуны күргән малайлар без. Хәзер менә шул җитми, – ди Илфат. – Кулың эш белсә, кесәң буш тормый. Ялкауланмаска гына кирәк. Аннары ир кешегә нинди генә эшкә тотынса да, янәшәсендә аңлаучы кеше булу мөһим. Ә минем бу яктан шөкер итәрлек. Сәрия канатландырып тора. Хәзер инде ул да миңа булыша. Икәү бергә булганда, бар да җиңел. Гаиләм белән бәхетлемен. Өч баламны чын кеше итеп үстерергә иде. Матур картлык телим үзебезгә. Кирәкле, кадерле булып яши алсак иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5332 данә
Гомуми тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 240

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+